**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2020 елның «29» апреленнән № 60-373

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 30.10.2017 ел, №30-175 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына үзгәрешләр кертү турында" һәм "Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибе хакында" Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 30.10.2017 ел, №30-175 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 18 пунктның 18.1 һәм 18.2 пунктларындагы "ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча "сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Указы белән билгеләнгән сроктан да соңга калмыйча" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль район Башлыгы В.М. Козлов